СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Решение** **Карар**

№5-7 от «01» июля 2026 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты Аппараты структурасына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының эшчәнлеген оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнары нормативлары турында” 2007 елның 17 декабрендәге 722 номерлы карары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. 2026 елның 01 августыннан Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторыннан муниципаль хезмәтнең сектор мөдире һәм баш белгече вазыйфасын чыгарырга, гомуми бүлекнең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторын бетерергә.
2. 2026 елның 01 августыннан Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенең цифрлы үсеш һәм мәгълүмати иминлек секторыннан сектор мөдире һәм әйдәүче белгеч муниципаль хезмәт вазыйфаларын чыгарырга.
3. 2026 елның 01 августыннан Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының гомуми бүлегеннән муниципаль хезмәт вазыйфаларына карамаган баш белгеч вазыйфасын чыгарырга.
4. 2026 елның 01 августында Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетында «Мәгълүматлаштыру, мәгълүматны яклау һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге» структур бүлекчәсен төзергә. Мәгълүматлаштыру, мәгълүматны яклау һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеген Башкарма комитетның эшләр идарәчесе буйсынуына билгеләргә.

000036

Төзелгән мәгълүматлаштыру, мәгълүматны яклау һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлегенә муниципаль хезмәтнең бүлек башлыгы вазыйфасын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларына карамаган баш белгеч вазыйфасын кертергә.

5. 2026 елның 01 августында Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру, мәгълүматны яклау һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге составында «Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторы» структур бүлекчәсен төзергә. Мәгълүматлаштыру, мәгълүматны яклау һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлегенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторына сектор мөдире, баш белгеч вазифаларын кертергә.

6. 2026 елның 01 августында Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече вазифасын кертергә.

7. 2026 елның 01 августыннан Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегеннән муниципаль хезмәтнең баш белгече вазыйфасын чыгарырга, бүлек начальнигы урынбасары вазыйфасын кертергә.

8. 2026 елның 01 августында Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый эш бүлегеннән муниципаль хезмәтнең баш белгече вазыйфасын чыгарырга.

9. 2026 елның 01 сентябрендә Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру эшләре бүлегенә муниципаль хезмәтнең баш белгече вазифасын кертергә.

10. 2026 елның 01 августыннан Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру эше бүлегенең кадрлар секторыннан һәм муниципаль хезмәтеннән муниципаль хезмәтнең сектор мөдире һәм баш белгече вазыйфаларын чыгарырга, оештыру эше бүлегенең кадрлар һәм муниципаль хезмәт секторын бетерергә.

11. Мамадыш муниципаль район Советыннан машина йөртүче вазыйфасын алып чыгарга.

12. 2026 елның 01 августында Мамадыш муниципаль районы Советында «Муниципаль хезмәт, кадрлар һәм бүләкләр бүлеге» структур бүлекчәсен оештырырга. Муниципаль хезмәт, кадрлар Һәм Бүләкләр бүлеген муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе карамагына билгеләргә. Оештырылган муниципаль хезмәт бүлегенә муниципаль хезмәтнең бүлек башлыгы һәм баш белгече, машина йөртүче вазыйфаларын кертергә.

13. Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына штат расписаниеләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

14. Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

15. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш
муниципаль районы
Башлыгы В.И.Никитин